| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 елның 1 октябре № 9

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата керемнәре турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 06 августындагы 658 номерлы карары нигезендә Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

2018 елның 20 апрелендәге 4 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата керемнәре турында» Нигезләмәгәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфасына бәйле рәвештә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының 1,03 тапкыр күләмендә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгелиләр.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында»(PRAVO.TATARSTAN.RU), «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Н.Габдрахманов